**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г. Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2025 елның 20 августы 1542 номер

КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025елның 04 августындагы 1453 номерлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яисә) урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренең балаларына уку елы башына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә яшәүче, мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яисә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән хәрби хезмәт узу турында контракт яисә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарының гаилә әгъзаларына социаль ярдәм чаралары системасын булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2025елның 04 августындагы 1453 номерлы «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яисә) урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләренең балаларына уку елы башына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибе турында» (алга таба_КАРАР) карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы 2.2 пунктчасында әтисе (әнисе) сүзләреннән соң «үги әтисе(баланың анасы белән рәсми никахта торучы)» сүзләрен өстәргә.;

1.2. Карарның 4 пунктында «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мәгариф идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе (Хөсәенова Л.И.)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга, «башкарма» сүзен төшереп калдырырга.;

1.3. Карарның 5 пунктында «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мәгариф идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе (Хөсәенова

Л.И.)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга.;

1.4. Өч абзацта 1.2 пунктның 3 абзацында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яисә) урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балаларга уку елы башына махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибе (алга таба – ТӘРТИП) атасы (анасы) сүзләреннән соң «,үги әтисе (баланың анасы белән рәсми никахта торучы)» сүзләрен өстәргә";

1.5. 1.5 пунктта. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мәгариф идарәсе» МКУ» сүзләрен «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 2.3 пунктын түбәндәге эчтәлекле «и» пунктчасы белән тулыландырырга:

«и) рәсми никахлашу турында таныклык (Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск, Херсонск өлкәләре территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар булган (булган) балалар өчен чыгарылган документлар;

1.6. 2.10 пунктында «20 августта» сүзләрен «29 августта» сүзләренә алмаштырырга.;

1.7. 2.12 пунктында «г» һәм «ж» пунктчаларын төшереп калдырырга;

1.8. 3.1 пунктында «25 августта» сүзләрен «29 августта» сүзләренә алмаштырырга;.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Г. Карсаловка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**